КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 март г.Казань № 344

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус сакланыла торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында


Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:


Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус сакланыла торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән (Татарстан Республикасы Мини-стрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2011 ел, 8 август, 641 нче; 2012 ел, 17 июль, 600 нче; 2013 ел, 27 март, 208 нче; 2013 ел, 1 июнь, 374 нче; 2013 ел, 6 июнь, 390 нчы; 2014 ел, 20 май, 335 нче; 2014 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 11 июль, 475 нче; 2016 ел, 21 июль, 493 нче; 2017 ел, 31 гыйнвар, 42 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 744 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы; 2018 ел, 21 май, 380 нче; 2019 ел, 26 март, 221 нче; 2019 ел, 28 май, 445 нче; 2020 ел, 5 февраль, 77 нче; 2020 ел, 6 октябрь, 909 нчы; 2020 ел, 4 ноябрь, 994 нче; 2022 ел, 28 февраль, 183 нче; 2022 ел, 16 июнь, 569 нчы; 2022 ел, 18 август, 853 нче, 2022 ел, 2 сентябрь, 953 нче, 2022 ел, 26 октябрь, 1144 нче, 2022 ел, 2 декабрь,


1277 нче, 2023 ел 18 февраль, 152 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына, “Арча муниципаль районы” бүлегенең “Казансу елгасы [28]” бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:


«Казансу елгасы [28]

| | |
|---|---|
| Статус | Төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан АССР Министрлар Советының 1978 елның 10 гыйнварындагы 25 номерлы карары<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 644 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы Арча, Биектау муниципаль районнары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| Башкарма хакимиятнең контрольдә тотучы дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Республика Татарстан
Арский муниципальный район
Республика
Татарстан
Высокогорский
муниципальный
район
Наласа
Арск
Качелино
Васильева Бука
Чемерцы
Татарская Айша
Стар.Чурилино
Чулпаново
Татарское Каедиково
Ашабаш
Якты-Кен
Русский Урмат
Камаево
Кзыл-Куль
Штырь
Венета
Бол.Верези
Сред.Верези


Республика Татарстан
Высокогорский муниципальный район
Сосмаги
Куркачи
Ямашурма
Шапши
Бимери
Сосновка
Кириллово
Хохлово
Байкал
Калинино
Клетни
Красн.Восток
Николаевка
лес Яныковский




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Табигать һәйкәленең озынлыгы 154 километр тәшкил итә.

Табигать һәйкәлен оештыру Казансу елгасын экологик чылбырда иң мөһим звено буларак саклауга нигезләнгән.

Елга кушылдыклар, балкалар һәм чокырлар үзәннәре белән кисешкән аз дулкынлы асимметрияле тигезлек буйлап уза. Бу тигезлек көньяк-көнбатышка таба гомуми төстәге калкулыклар белән тоташкан.

Үзәнлеге аз дулкынлы, яхшы эшләнгән, трапецеидаль, тау битләренә хас сөзәк к һәм тәбәнәк батынкылыклы. Елганың киң үзәне ачык беленеп торган тоташ ике яклы тигез булган (1 километрга кадәр) тугайны кисеп үтә. Казансу елгасының биек ярлары, Иделгә якынлашкан саен, йомшаграк билгеләр ала. Казансу елгасы ярларын актарган аерым урыннарда яр буйларын юалар, соңгылары текә ярларның характерына ия. Казансуның түбәнге агымы, сусаклагыч идән астында булып, суднолар йөрү өчен яраклы киң култыкка әверелгән. Күп сандагы кушылдыклар куе елга челтәре хасил итә.

Уртача сулыктагы елга, кушылдыклар көйләнгән. Елганың туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары (70 процент). Гидрология режимы биек язгы ташу һәм аз вакытлы түбән тирәнлек белән характерлана.

Ел эчендә агымның бүленеше тигез түгел. Еллык агымның уртача катлавы 92 - 165 миллиметр 85 - 120 миллиметр булса, язгы ташу чорына туры килә, аның

озынлыгы - 30 көнгә якын. Кышкы чор өчен дәвамлы (153 көн) тотрыклы боз (боз калынлыгы - 78 сантиметр) хас.

Елганың сыйфат составы сульфатн-гидрокарбонат-кальцилыдан алып гидрокарбонат-сульфат-кальцийлыга кадәр үзгәрә. Су язда уртача каты һәм түбән тирәнлектә бик каты, язын минеральләштерү кече һәм түбән тирәнлектә югары.

Коловраткаларның 52 төре, 37 - ветвистоуслар һәм 29 - ишкәкле кысласыманнар, 20 бентос организмнары таксоны билгеле.

Сак чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән табигать һәйкәлен саклау режимы нигезендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин